РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«26» август 2022г. с. Тюлячи № 154

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 21 июлендәге 9760/22 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___» _______ 2022 № _____
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы

Әлеге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары,«Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына «Контроль» модуленең эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнелгән һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинг тәртибен билгели:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Теләче муниципаль районында декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау өчен «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) җаваплы.

1.2. Белешмә мәгълүматы

Әлеге регламентның максатлары өчен муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булуы» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла, алар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән.

## 2. Исәп-хисап стандарты, җыю тәртибе һәм белешмәләр бирү

Декомпозияләнгән ярдәмче күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан хисап чорында югарырак күрсәткечләр җыюны гамәлгә ашыра.

Муниципаль район буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3. Мәгълүматларның составы, срогы һәм бирү рәвеше

Балаларны исәпкә алу һәм мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан мәгълүмат бирү формасы таблицада күрсәтелгән.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны

| № т/б | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешманың аталышы | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Хисап аеннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр квартал саен мәгълүмат бирү срогы | Дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны | Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |